# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

«Юл хәрәкәте, транспорттан файдалану, юл-урам челтәрен һәм хәрәкәтне оештыруның техник чараларын тоту кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

1 статья. «Юл хәрәкәте, транспорттан файдалану, юл-урам челтәрен һәм хәрәкәтне оештыруның техник чараларын тоту кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, №№ 5,6-7; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1995, №№ 7-8; 1998, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 17 статьяда:

беренче, икенче, өченче өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Исерек килеш транспорт чараларын йөртүләрен билгеләү өчен нигезләр җитәрлек булган транспорт чараларын йөртүчеләр яисә башка затлар, шулай ук транспорт чараларын йөртү хокукы булмаган, яисә бу хокуктан мәхрүм ителгән, яисә юл хәрәкәте кагыйдәләрендә каралган документларын үзе белән алмаган, яисә әлеге Законның 2 статьясындагы өченче, дүртенче өлешләрендә каралган документларны үзе белән йөртмәгән затлар транспорт чарасын йөртүдән чикләштерелергә, ә транспорт чарасы - тоткарлау сәбәпләре бетерелгәнче тоткарланырга тиеш.

Транспорт чарасын тоткарлау эчке эшләр органнарының урындагы заты тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

Транспорт чарасын тоткарлау аерым беркетмә белән рәсмиләштерелә яисә административ хокук бозу турындагы беркетмәгә тиешенчә язып куела.»;

дүртенче өлештән «һәм ташыла торган йөкне» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Транспорт чарасын тоткарлаган урындагы зат аның хуҗасына китерелгән зыян өчен транспорт чарасын хокукка каршы тоткарлаган очракта гына җаваплы була.»;

искәрмәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Искәрмә. Транспорт чарасыннан файдалануны аны махсус бүлеп бирелгән саклануучы урынга урнаштыру юлы белән тыюны тоткарлау дип аңларга кирәк.».

2. 18 статьяның икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге затларның исереклек халәтен таныклауга җибәрү һәм аны таныклау законнарда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.».

3. 19 статьяның икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Транспорт чараларын йөртү хокукыннан мәхрүм итү вакыты беткәннән соң, йөртүче таныклыгын әлеге затка кайтарып бирү законнарда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.».

2 статья. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2000 елның 20 декабре
№ 543